**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

№ 16 Кәрәкәшле ав. 07.10.2017 ел

*Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау кагыйдәләре турында»28.03.2012 ел, № 4 карарына үзгәрешләр кертү хакында*

Ютазы районы прокурорының 28.08.2017 ел №02-08-01-2017/14 протестын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Кәрәкәшле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә Төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау кагыйдәләренә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 28.03.2012 ел, №4 карары белән расланган (28.06.2014 ел, 11 санлы карары белән үзгәрешләр кергән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 3.1.1 Пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә : « 3.1.1. Территорияне карап тоту һәм җыештыру эшләрен оештыру өчен җаваплылык әлеге территориядә милек, биләү, файдалану, аренда хокукларында булган затларга йөкләнә.»
1.2. 3.1.2 Пунктны гамэлдэн чыгарырга.
1.3. 4.1.1 Пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: « 4.1.1 .Җирлек территориясен санитар чистарту һәм карап тоту юридик һәм физик затлар тарафыннан милек, биләү, файдалану, аренда хокукларындагы территорияләр чикләрендә санитария нормалары һәм кагыйдәләрендә, әлеге Кагыйдәләрдә, башка муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.»
1.4. 5.2.4 пунктында. «һәм аңа якын территория " сүзләрен төшереп калдырырга.
1.5. 5.3.1 пунктыннан төшереп калдырырга: дүртенче абзацны, өченче абзацның өченче җөмләсен.
1.6. 9.1.2 Пунктын гамэлдэн чыгарырга.
1.7. 9.1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «9.1.3.Юридик һәм физик затлар үзләренең милек, биләү, файдалану, аренда хокукларындагы территорияләре чикләрендә түбәндәге чараларны үткәрүне тәэмин итә:
- агачлар һәм куаклар биналардан һәм корылмалардан рөхсәт ителә торган минималь ераклыкларны исәпкә алып, агротехник таләпләрне үтәп утыртыла;
- чаптырылган үлән 3 тәүлек дәвамында җыеп алынырга тиеш;
- чүп-чарны вакытында җыештыру һәм кардан чистарту эшләре бара;

- киселгән агачларны төп магистральләрдә бер тәүлек эчендә һәм башка территорияләрдә ике тәүлек дәвамында чыгаралар. Көч линияләренең ток йөртүче үткәргечләренең һәм контакт челтәрләренең саклау зонасында (1 м радиуста) агач ботакларын вакытында кисүне алар карамагындагы оешмалар тәэмин итә.»

1.8. 9.1.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: « 9.1.14. Милек, биләү, файдалану, аренда хокукларында үзләренә караган территорияләр чикләрендә юридик һәм физик затлар тарафыннан яшел утыртмаларның корткычлары һәм авырулары белән көрәшү буенча тиешле чаралар күрелергә, сулыкларны чиста тоту тәэмин ителергә тиеш.»

2. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә: Кәрәкәшле авылы, Мирфатыйх Зәкиев ур., 47 йорт, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.и Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А. Г. Дәүләтгәрәев